Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 12 (12)

22 декабрь 2011 ел

## • Ике авыз сүз

19 декабрь көнне ректоратның чираттагы утырышы үтте. Көн тәртибендә түбәндәге мәсьәләләр каралды: КФУның Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтының үсеш программасын тәкъдим итү (тышкы элемтәләр буенча проректор Л.Латыйпов); КФУның Югары банк мәктәбе презентациясе (Югары банк мәктәбе директоры И.Шәйхетдинов); Үсеш программасының барышы турында хисап (икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин); 2012 елда абитуриентлар кабул итү эшләренең торышы буенча мәгълүмат (кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе С.Ионенко).

Л.Латыйпов сүзләренә караганда, җир шарының 50% халкы Көнчыгышта яши. Шуларның 80%ы – үсеп баручы илләрдә. Социологларның күзаллаулары да чынга ашып килә: алар фикеренчә, XXI гасырда кешелек җәмгыятендә Якын, Урта һәм Ерак Көнчыгыш илләренең абруе артачак. Шуңа күрә университетта Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтының эшчәнлеген яңартып, заман таләпләренә туры китереп тору шарт. И.Гафуров презентация турында үз фикерләрен җиткерде һәм Көнчыгышны өйрәнү бүлекләре булган башка вузлар белән тыгыз элемтәдә торырга кирәк дигән тәкъдим ясады.

И.Шәйхетдинов докладында сүз киләчәктә вузда югары классификацияле банк хезмәткәрләре әзерләү турында барды. Чыгыштан соң ректор университетның бу яңа бүлегенә Икътисад һәм финанс институтының банк эшләре кафедрасы белән элемтәдә торырга кирәклеген әйтте.

КФУның Үсеш программасын тормышка ашыру кысаларында булган үзгәрешләр турында М.Сафиуллин сөйләде. Ул уку йортына кирәк булган фәнни һәм укыту җиһазлары алу юнәлешендә төзелгән килешүләргә бәйле мәгълүмат җиткерде.

С.Ионенко кабул итү комиссиясендәге кайбер үзгәрешләргә басым ясады. Мәсәлән, ташламаларга ия абитуриентка гаризасын бары тик бер вузга һәм бер белгечлек буенча гына тапшырырга мөмкин булачак. Башка гаризалары гомуми нигезләмәләр буенча аерым очракларда гына каралачак. Кабул итү имтиханнарының санын да дүрттән өчкә калдыру планлаштырыла.

Утырыш азагында М.Сафиуллин КФУның Идел буе федераль округының Үсеш стратегиясен тормышка ашыруда катнашуы турында сөйләде.

• • • •

19 декабрь көнне КФУның Яр Чаллы филиалы филология һәм журналистика факультетында V кафедраара «Мәдәният контекстында журналист портреты» студентлар конкурсы узды. Студентлар жюри игътибарына шәһәрнең танылган журналистлары төп геройлар булган төрле иҗади проектлар тәкъдим итте. Йомгаклап, филология һәм журналистика факультеты деканы Наталья Федотова: «Бу – журналист белән журналистка аралашырга мөмкинлек бирә торган чара. V курс студентлары өчен соңгы сынауларның берсе булган конкурс без әзерләгән белгечләрнең ни дәрәҗәдә профессионал икәнлекләрен дә аңларга ярдәм итә», – диде.

• • • •

Шушы көннәрдә шулай ук Яр Чаллы филиалында «Мәгариф һәм хезмәт базары: үзара йогынты һәм үсеш» дигән II Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция узды. Биредә 200 дән артык Мәскәү, Казан, Яр Чаллы, Саратов шәһәрләреннән, Россия, Казакъстан, Азәрбайҗанның төрле төбәкләреннән министрлык һәм идарә, мәгариф оешмалары, эш белән тәэмин итү үзәге вәкилләре катнашты. Чыгыш ясаучыларны эшкә урнашу, кадрлар җитмәү яисә артык күп булу, хезмәт хакына бәйле проблемалар борчый.

• • • •

17 декабрь көнне Мәктәпкәчә белем бирү системасы өчен инновацион идеяләр III Идел буе конкурсына йомгак ясалды. Аны Педагогика һәм психология институтының педагогика һәм мәктәпкәчә белем бирү методикасы кафедрасы оештырды. Чарада 367 кеше катнашты. Шуларның 40ы I һәм II дәрәҗә дипломнар белән бүләкләнде.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*




Энже Ибраһимова фотосы

# Елның иң-иңнәре

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

21 декабрь көнне КФУның Актлар залында күркәм традициягә әверелгән, быел бишенче тапкыр старт алган «КФУның ел студенты – 2011» бәйгесенә йомгак ясау тантанасы узды.

Уку йортындагы талантлы студентларны санап бетереп кенә булмый. Аларның иң-иңнәрен барлау, башкаларга үрнәк итеп күрсәтү, алга таба үсәргә стимул булдыру өчен, мондый чараларның әһәмияте бик зур. Фестивальдә катнашучыларны, укытучылар һәм студентларны сәламләп, КФУ ректоры Илшат Гафуров: «Биредә иң актив, зур уңышларга ирешкән студентлар көч сынашты. Быелгы фестивальнең төп үзенчәлеге: ул өч уку йортын берләштергән федераль университетта үтте. Истәлекле бүләкләрдән тыш, һәр финалистка – 5, җиңүчеләргә – 10, «Ел студенты» һәм «Укытучы-тәрбияче» номинациясендә җиңүчеләргә 25 мең күләмендә акча биреләчәк», – диде.

Елдагыча, фестивальгә кабул ителгән эшләр номинацияләргә бүленгән иде. Чарада катнашкан һәр институт-факультет вәкиле актив, аның җиңү теләге көчле.

Беренче булып, «Иң яхшы җәмәгать эшлеклесе – 2011» номинациясендә катнашкан финалистларны бүләкләделәр. Биредә студентлар үзидарәсе эшчәнлегенә, университетта социаль проблемаларны хәл итүгә, республика күләмендә студентлар сәясәте үсешенә өлеш керткән студентлар көч сынаша. Төп җиңүче – Идарә итү һәм территориаль үсеш институты студенты Никита Беликов.

«Студентларның иң яхшы иҗтимагый оешмасы – 2011» номинациясендә проектларның актуальлеге белән вуз, республика яшьләр аудиториясен кызыксындырган оешмалар бүләкләнә. Юридик факультетның фәнни оешмасы (җитәкчесе – Татьяна Якунина) иң-иңнәрдән дип табылды.

**Ахыры 2нче биттә.**

## • Халык җәүһәрләре

# Тере традиция

Бу атнада Яр Чаллы шәһәренең «КамАЗ» мәдәният йортында халык кәсепләре, һөнәрләре һәм декоратив-гамәли иҗат буенча V Бөтенроссия «Тере традиция» фестивале узды.

Быелгы фестиваль Юбилеен билгеләде. Бишенче мәртәбә узучы чара илебезнең төрле почмакларыннан җыелган «алтын кулларны» берләштерде. Фестивальдә Россиянең 40 төбәгеннән 250дән артык оста катнашты. Татарстан Республикасын Яр Чаллы, Казан, Алабуга, Зәй, Әлмәт, Түбән Кама, Кукмара, Алексеевск шәһәр һәм район оста куллары тәкъдим итте.

Оештыручылар фестивальнең географиясе артуы турында гына түгел, ә эшләрнең сыйфаты яхшыруын да искәртә.



**Ахыры 2нче биттә.**

# Тере традиция

**Башы 1нче биттә.**

Быел кул эшләрен яратучылар агач, металл, тире һәм күн эшләнмәләрен, балчыктан, каен тузыннан ясалган әйберләрне, милли уенчыкларны, чын таштан эшләнгән бизәнү әйберләрен карый алды. Күргәзмәгә килүчеләр биредәге матурлыкка сокланып, аларны алып кына калмады, хәтта үзләре үк ясап карады, мастер-классларда катнашты.

Фестивальдә балалар һәм зурлар иҗат коллективлары катнашты, халкыбызның күркәм традицияләрен, матур гореф-гадәтләрен яктырткан театральләштерелгән чыгышлар тәкъдим ителде. Шулай ук Яр Чаллы, Кукмара, Казан фольклор киемнәре мода театрлары әзерләгән дефиле беркемне дә битараф калдырмады. Халык уен коралларында башкарылган милли көйләребез һәркемнең күңеленә хуш килде. Элдагыча оста куллар һәм алар иҗаты турында радиогазета сөйләп торды.

КФУның Филология һәм сәнгать институты «Tatar style» костюм студиясенең (җитәкчесе – сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасы доценты Р.Сәләхова) «Моңлы Казан» коллекциясе, әлеге институтның сәнгать бүлеге каршындагы Кукмара кече дизайн академиясенең «Үткәнгә кайту» коллекциясе тамашачыларда зур соклану хисләре уятты.

**nabchelny.ru сайты**

# Елның иң-иңнәре

**Башы 1нче биттә.**

«Иң яхшы профорг – 2011» номинациясендә институт яки факультет дәрәҗәсендә социаль сорауларны чишүдә актив ярдәм иткән студентлар катнаша. Филология һәм сәнгать институты студенты Гөлназ Мәрданова калган финалистлардан өстен чыкты.

«Иң яхшы волонтер – 2011» номинациясендә катнашучы һәрьяктан актив булырга һәм сәламәт яшәү рәвеше алып барырга тиеш. Вуз, республика дәрәҗәсендәге спорт чараларында һәм 2013 елда узачак Җәйге Универсиадага бәйле проектларда катнашу мөһим. Безнең университет студентлары да мондый чаралардан читтә калмый, әлбәттә. Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты студенты Вероника Антонова җиңүгә лаек булды.

«Тулай торакның иң яхшы советы – 2011» номинациясендә тулай торакны тәртиптә, чиста тоту буенча студент үзидарәләре эшчәнлеген тикшерәләр. Әлеге номинациянең төп җиңүчесе – Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты студентлар советы (җитәкчесе – Эльвира Сафина).

«Иң яхшы студент проекты – 2011» номинациясе вуз, республика өчен әһәмиятле булган проектны бүләкли. Биология һәм туфракны өйрәнү факультетының «Табигатьне саклау хезмәте» проекты иң яхшылардан дип табылды.

«Иң яхшы аспирант – 2011» номинациясендә җиңү фән өлкәсендә зур уңышлары булган аспирантларга бирелә. Әлеге номинация буенча бүләк быел беренче тапкыр тапшырыла. Биология һәм туфракны өйрәнү факультеты аспиранты Рената Миңнуллина җиңүгә лаек булды.

«Интеллект – 2011» номинациясендә фәнни-тикшеренү эшләрендә, семинар-конференцияләрдә актив катнашкан яхшы билгеләргә укучы студентлар көч сынаша. Бутлеров исемендәге Химия институты студенты Ләйсән Әмирова бу номинациянең төп җиңүчесе булды.

«Иң яхшы мәгълүмат чарасы – 2011» номинациясе университет тормышын басма, видео- һәм фотожурналистикада актив яктыртып барган студентларны барлый.



Энҗе Ибраһимова фотосы

Журналистика һәм социология факультеты студенты Ксения Кадочникова иң яхшылардан дип табылды. Безнең коллегабыз – фотохәбәрче Энҗе Ибраһимова лауреат исеменә лаек булды.

«Иң яхшы иҗади шәхес – 2011» номинациясендә катнашучыларның шулай ук иҗат, мәдәният өлкәсендә җулаган уңышлары күп булу мөһим роль уйный. Фестивальгә КФУның филиалларыннан конкурсантлар килгән иде. Бу номинациядә Яшел Үзән филиалы студенты Айнур Җамалетдинов җиңүгә ирешә.

«Иң яхшы иҗат коллективы – 2011» номинациясе уку йорты, республика күләмендәге конкурс-фестивальләрдә актив катнашып, җиңүләр яулаган иҗат коллективларын барлау өчен кирәк. Филология һәм сәнгать институтының «Tatar style» костюм студиясе (җитәкчесе – Рада Сәләхова) иң яхшы коллектив дип табылды.

«Институтта иң яхшы мәдәни-массакүләм эшләр оешмасы – 2011» номинациясендә мәдәни-оештыру эшләрендә актив катнашучылар көч сынаша. Бу номинациядә Физика институты студенты Асия Гыйззәтуллина җиңде.

«Ел ачышы – 2011» номинациясе II курс студентлары катнашу белән үзенчәлекле. Алар җәмәгать, иҗат, фән һәм спорт өлкәләрендә дә актив катнашырга тиеш. Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты студенты Лилия Әхмәтҗанова иң-иңнәрдән дип табылды.

«Иң яхшы спортчы – 2011» номинациясендә катнашучылар саны күп түгел. Биредә спорт өлкәсендә иң зур уңышларга ирешкән спортчыларны зурлыйлар. Җюри әлеге номинацияне икегә бүлеп тапшырды. «Профессионаллар арасында иң яхшы спортчы – 2011» исеменә Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты студенты Юлия Зарипова лаек булды. Ә калган дүрт финалист: Илдар Әсхәдуллин (Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты), Алинә Сафиуллина (Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты), Рәдиф Шәрифуллин (Икътисад һәм финанс институты), Сергей Шумихин (КФУның Алабуга филиалы) шулай төп җиңүне бүлеште.

«Иң яхшы укытучы-тәрбияче – 2011» номинациясендә җиңүчене оештыру комитеты рәисе билгеләде. Биредә катнашкан финалистларны залдагы тамашачы басып каршы алды һәм көчле алкышларга күмде. Алар һәркайсы зур хөрмәткә һәм җиңүгә лаек! Химия институтының органик булмаган химия кафедрасы доценты Галина Боос, биология һәм туфракны өйрәнү факультетының зоология һәм умырткасызлар кафедрасы профессоры, биология фәннәре докторы Флюра Соколина, журналистика һәм социология факультетының социология кафедрасы доценты Сөмбел Әхмәтова, Экология һәм география институтының ландшафт экологиясе кафедрасы профессоры Николай Торсуев, Филология һәм сәнгать институтының татар теле кафедрасы доценты Рауза Асылгәрәевалар «Иң яхшы укытучы-тәрбияче – 2011» исеменә лаек булды.

«Ел студенты – 2011» номинациясендә өлкән курс студентлары катнаша. Һәр өлкәдә актив, яхшы укучы студентлар арасыннан иң-иңен билгеләү җиңел түгел. Конкурсантлар көчле, ләкин төп җиңүче булырга тиеш. Бу мактаулы исем юридик факультет студенты Диана Галиевага бирелә. Җиңүче кыз барлык укытучыларына, җитәкчеләренә һәм, әлбәттә, залда утыручы әти-әнисенә рәхмәт сүзләре җиткерде.

● Россиядә космонавтика елы

# Озын юллар аша

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

Шушы көннәрдә КФУга СССР һәм РФ космонавтлары делегациясе килде. Алар арасында Анатолий Арцебарский, Александр Баландин, Василий Циблиев, Михаил Корниенко бар иде. Әлеге визит Россиядә космонавтика елына багышланган иде.

Мәртәбәле кунакларга Казан университеты тарихы музее директоры Стелла Писарева экскурсия оештырды. Alma mater чоры, ачышлар, университет язмышы белән бәйле галимнәр һәм сәнгать кешеләре турында сөйләде. Экскурсиядән соң космонавтлар Мәртәбәле кунаклар китабында үз теләкләрен калдырдылар. Очрашу уңаеннан, кунаклар үз фикерен җиткерергә ашыкты.

Советлар Союзы герое, очучы-космонавт, очучы-сынаучы Анатолий Арцебарский: «Казан – бай тарихлы һәм зур мөмкинлекләр тудырылган шәһәр. Шуңа күрә студентларга бер генә теләк: эшләргә, эшләргә һәм эшләргә. Гомумән, шуны ассызыклап үтәсе килә: студентларның күзләре янып тора. Алар космонавтика сәнәгатенә битараф түгел. Бу – чын яшь буын», – диде.

«Космонавт булу өчен, дөрестән дә, бик озын юл үтәргә кирәк. Шәхсән мине, гариза биреп, 20 ел үткәч кенә төркемгә кабул иттеләр. Ә беренче очуга кадәр – тагын 13 ел. Ут аша да, су аша да үтәргә туры килде. Бу өлкәне сайлаган кешеләргә ике теләк әйтәсем килә: беренчедән, үз максатыңа ирешү өчен, озын һәм авыр юл үтәргә кирәк, икенчедән, зур хезмәт хакына өметләнергә кирәкми», – дип фикерләрен җиткерде очучы-космонавт, Россия Федерациясе Герое Михаил Корниенко.

# «УРа»га 1 яшь!

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

КФУның Яр Чаллы филиалы студентлары үтә актив булулары белән аерылып тора. Шушы көннәрдә алар «УРа» радиостанциясенең бер яшьлек юбилеен билгеләп узды. Бәйрәм уңаеннан, тыңлаучыларын уеннар, истәлекле бүләкләр, котлаулар һәм, әлбәттә, яхшы кәеф белән сөендерделәр.



Бер яшьлек бала белән чагыштырып булмый әлеге мәгълүмат чарасын. Баладан аермалы буларак, алар инде иркен сөйләшә, тәпи йөрмәсә дә, кирәк җиргә мәгълүматны кызыклы һәм мавыктыргыч итеп тапшыра. Бүгенге көндә КФУ филиалының ике корпусында да радионы тыңлау мөмкинлеге тудырылган. Гадәттә, алып баручылар тәнәфестә, эфирга чыгып, студентларның ялын файдалы итә. Туры эфирда уен-көлке, җыр белән бергә укуга бәйле чыгышлар да була. Тыңлаучылар игътибарына атнасына биш көн рәттән «Актуаль музыка», «Рок көне», «Викторина», «Татар яшьләре», «Яңалыклар» кебек тапшыруларны журналистика һәм филология факультеты студентлары тәкъдим итә. Кунакка иң актив студентлардан башлап, филиалның дәрәҗәле укытучылары, профессорлар һ.б. мәртәбәле шәхесләр чакырыла. Студентлар тормышына бәйле проблемаларны күтәреп, аларны чишү юлларын күрсәткән җанлы чыгышлар һәркем өчен кызыклы.

Студиядә журналистика факультетында белем алучы студентлар радиожурналистика өлкәсендә тәҗрибә тупларын ала. Дәресләр вакытында алар радиотапшырулар әзерли, үзләрен диджей ролендә сынап карап, яңалыклар укый. Моннан тыш, факультетның башка студентлары да биредә шөгыльләнә. Телевизион материаллар өчен синхроннар, тавыш яздыралар, җиһазларны өйрәнәләр.



Радиостудия хезмәткәрләренең мактанырлык уңышлары да шактый. Алар хәтта ел саен «Медиа Союз» массакүләм мәгълүмат чаралары бөтенроссия иҗтимагый оешмасы уздыра торган иҗат конкурсында, Укытучылар елына багышланган радиосюжет белән катнашып, икенче урынны яулый. Шулай ук III «Жираф-СМИ» студент һәм мәктәп укучылары массакүләм мәгълүмат чаралары халыкара фестивалендә, «Медиа Поколение» студентларның массакүләм мәгълүмат чаралары бөтенроссия конкурсында катнашуы игътибарга лаек.

Редакция вәкилләре актив, креатив, тапшыруларны һәр студентка, укытучыга барып ирешерлек итеп алып бара. Алга таба зур планнар корып, яңа идеяләр белән яши алар. «УРа» радиостудиясе эфирларын Интернет челтәре аша дөнья күләменә чыгарырга хыяллана. Дөрес эшлисез, дип әйтәсе килә, чөнки Яңа елда барлык хыяллар да чынга аша бит!

● Алар бездә укыган

# Хәтерлим мин әле бүгенгедәй...

**Регина РАЯНОВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты



Җәйнең бик матур бер эссе көне иде. Миңа йомыш белән Уфа шәһәренә барырга туры килде. Кисәк кенә башыма бер уй килде: монда кадәр килгәч, Суфиян абый Поварисовны күреп, аңа үзебезнең университетта чыгып килгән «Яшьлек тавышы» газетасында басылган мәкаләмне тапшыра алсам, ничек сөенер иде! Күңел дигәнең әздән генә дә күкләргә оча да китә бит ул... Ә монда Казаннан, С.Поварисов ничә еллар элек укып кайткан университеттан кунак килсә?!

«Тырышкан табар, ташка кадак кагар», – дип өлкәннәр белми әйтми икән. Ничек итсәм, шулай итеп, адресын табып, әлеге теләгемне чынга ашырдым.

Ишектән килеп керүгә, мине мәһабәт гәүдәле, чал чәчле, тормышның күп кенә сикәлтәле юлларын үткән, мөлаем йөзле Суфиян абый үзе каршы алды. Ялгышмаганмын икән, минем кунакка керүемне ул бик хуплады. Үземнең Дүртөйле районыннан (Башкортстан Республикасы) икәнлегемне әйткәч: «Үзебезнең кеше икәнсең», – дип сөенде.

Суфиян абый сүзен авыр да, шул ук вакытта бәхетле дә булган балачак елларыннан сөйләп алып китте. Ул шулкадәр төзек һәм камил тел белән сөйли. Онытылып, күңелгә рәхәтлек алып, көн буе тыңлап утырырга була. Ләкин мине күбрәк 1951-1955 еллар – аның Казан педагогия институтының тарих-филология факультетында укыган чоры кызыксындырды. Институтта уку дәверендә С.Поварисов татар, башкорт, казакъ, кыргыз, үзбәк, уйгур телләренең фонетик, морфологик, лексик үзенчәлекләрен чагыштырып өйрәнә. Аның бу хезмәтен институт укытучылары югары бәяли.

Хезмәт юлын 1955-1958 елларда Актаныш районының Бурсык урта мәктәбендә директор булып башлап җибәрә ул. Ләкин кайларда гына йөрсә дә, туган ягы аны үзенә тарта һәм ул Башкортстанга кайта. 1958-1960 елларда «Кызыл таң» газетасында әдәби хезмәткәр була. 1960 елдан алып Башкорт дәүләт университетының татар теле бүлегендә укыта һәм бүгенге көндә дә ул – студентларның яраткан, тәҗрибәле остазы.

Күренекле галим һәм язучы С.Поварисов төрле өлкәләрдә актив эшли. Галим буларак, стилистиканы фәнни өйрәнүгә ул күп көч сала. Әдип буларак, төрле жанрларда иҗат итә. Күп кенә шигырьләр һәм ике поэма бастыра. Авторның поэзиясенә лирик җылылык, күтәренке пафос, тематик төрлелек хас. Образлы, җанлы тел белән язылган повесть-хикәяләрендә уңай геройлар – бүгенге көн сулышы белән яшәүче, искелеккә каршы аяусыз көрәшүче, яңа, югары идеаллар белән янучы матур күңелле кешеләр. Төрле тәнкыйть мәкаләләрендә ул үзен әдәбиятның идея-эстетик юнәлешен дөрес аңлаучы теоретик итеп күрсәтте. С.Поварисов галимнәр, язучылар, вуз укытучылары арасында хезмәт сөючән, тырыш, принципиаль, кешелекле булуы белән аерылып тора.

Менә шулай, «бер утыру – үзе бер гомер», дигән кебек, бик күп мәгълүмат туплап, Суфиян абыйга чиксез зур рәхмәтләремне белдереп, күңелләрдә озак сакланырлык тәэсирләр алып кайтып киттем.

Ә күптән түгел генә тагын бер шатлыклы хәбәр килеп иреште. Суфиян Поварисовка Башкортстанның халык язучысы дигән исем бирелде.

● Очрашу

# Теле барның - иле бар

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Шушы көннәрдә КФУның Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең белемен камилләштерү һәм яңадан әзерләү үзәгендә Татарстан Республикасының төрле районнарыннан килгән татар теле һәм әдәбияты укытучылары, 72 сәгатькә исәпләнгән ике атналык курсларда белемнәрен камилләштереп, университет галимнәренең лекцияләрен тыңлап, Казан шәһәре мәктәпләрендә үткәрелгән семинарларда катнашып, мастер-класслар күрсәтеп, тестлар тапшырып, проектлар яклап, вакытның узуын сизми дә калдылар.

Ә бит әле бу эшчәнлектән тыш дәресләрдән соң аларны театр, концерт заллары каршы алды. Язучылар, шагыйрьләр, күренекле сәнгать эшлеклеләре дә укытучылар белән очрашуга бик теләп килделәр. Бигрәк тә бу курстагы ана теле укытучыларында Кытай иленең матур гына Чишмә исемле татар авылыннан бабайларының туган нигезе булган Татарстанга укырга килгән Назар Морат белән очрашу зур тәэсир калдырды. Назарның думбрада оста итеп уйнап, рәхәтләнеп татарча, казакъча, уйгурча, кытайча җырлавына сокланмыйча мөмкин түгел иде. Ул бу уку елында Филология һәм сәнгать институтының татар теле тарихы һәм төрки тел белеме кафедрасы укытучылары ярдәме белән татарча сөйләшергә өйрәнә. Ә киләсе елга Сәнгать академиясенә укырга керергә җыена. Әти-әниләре – укытучылар.

Быел Казанга Назар Морат кебек талантлы 22 татар баласын җыеп алып килгән Торсынтай әфәнде дә катнашты бу очрашуда. Аның туган телгә, туган җиргә багышланган озын-озын шигырьләрне яттан сөйләве дә, татар тарихын яхшы белүе дә кемне генә дулкынландырмады икән?! 2003 елда Татарстанның Беренче Президенты М.Шәймиевнең Кытайда яшәгән татар балаларына Казанда уку мөмкинлеге тудыруын белгәч, шунда яшәүче татарлар белән үткәрелгән зур бәйрәмне халык әле дә онытмый. Бездә укып киткән бер буын татар студентлары үзләрендә бик җитди урыннарда эшли дә башлаганнар. «Безнең максатыбыз – Кытай җирендә үзебезне югалтмыйча, татар кешесе булып сакланып калу», – ди Назар Морат.



● Халыкара багланышлар

# Мароккога «сәяхәт»

**Гөлшаһидә ДАУТОВА,**
ifi.kpfu сайты хәбәрчесе

15 декабрь көнне КФУның Филология һәм сәнгать институтында ел саен уздырыла торган «Гарәп мәдәнияте көннәре» фестивале ачылды. Ул быел Марокко Патшалыгы көннәренә багышланды. Чараны оештыручылар булып «Әл-Хәдәра» Гарәп мәдәнияте үзәге, Марокко Патшалыгы Илчелеге белән берлектә ТР Президенты каршындагы тышкы элемтәләр департаменты тора.



Ленар Мөхәммәтшин фотосы

Чараның тантаналы ачылышында КФУ ректоры Илшат Гафуров, Марокко Илчелегенең РФдәге Гадәттән тыш һәм тулы хокуклы вәкиле Әбделкадер Лешехеб, ТР Президенты каршындагы Тышкы элемтәләр департаменты директоры – халыкара мәсьәләләр буенча ТР Президенты ярдәмчесе Искәндәр Мөфлиханов, «Әбдел Мәликә Әс-Саади» университетының филология факультеты деканы Земмори Мөхәммәд Сәәд, КФУ, РИУ, «Мөхәммәдия» югары мөселман мәдрәсәсе студентлары, Казанның 149 нчы, 18 нче, «Госмания», Яшел Үзән шәһәренең 1 нче мәктәбе укучылары катнашты.

Шушы көннәрдә ТР Президенты Рөстәм Миннеханов Әбделкадер Лешехеб белән узган очрашуда Татарстан һәм Марокко вузлары арасындагы хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куйды. «Без студентларның Мароккода белем алуын һәм сезнең студентларны Казан вузларына җибәрүегезне телибез», – диде Рөстәм Миннеханов. Мондый тәҗрибә безгә яхшы таныш, чөнки Татарстаннан 30 дан артык студент Мароккода инде стажировка үткән. Рөстәм Миннеханов Татарстанда уза торган Марокко мәдәнияте көннәре әлеге илне тагын да ныграк өйрәнергә һәм сату-алу, икътисад мөнәсәбәтләрен ныгытырга ярдәм итәчәген ассызыклады.

Сәламләү сүзендә ректор Илшат Гафуров мондый фестивальләрнең 1999 елдан бирле уздырылуын һәм һәр елны төрле гарәп илләренә багышлануын әйтте. «Марокко Патшалыгы – безнең иң зур партнерыбыз. 3 ай дәвамында Мароккода стажировка үткән студентлар бик канәгать булып, яңадан сезнең илгә бару теләге белән кайттылар. Без көнчыгышны өйрәнүче белгечләрне әзерләүгә зур игътибар бирәбез, ә гарәп телен КФУда 260 тан артык студент өйрәнә», – диде ректор.

«Гарәп мәдәнияте көннәре» фестивале кысаларында гарәп теле буенча олимпиада, татар, марокко, рус халык ашлары конкурсы, марокко милли киемнәрен тәкъдим итү чарасы узды. Филология һәм сәнгать институтының уку залында традицион марокко эшләнмәләре, картиналары күргәзмәсе дә эшләде. «Мароккода туризм» стенды тәкъдим ителде.

Әбделкадер Лешехеб әйткәнчә, әлеге фестиваль Татарстан белән Марокко арасындагы хезмәттәшлекне ныгытуның төп чарасы булып тора. «Моннан тыш, безнең илләр арасында мәдәният, дин һәм тарих өлкәсендә уртаклыкларыбыз күп», – диде ул. Искәндәр Мөфлиханов исә Татарстанда гарәп телен өйрәнүчеләрнең күп булуын әйтте. Телне мәдәниятне белмәгән килеш өйрәнеп булмый, шуңа күрә фестиваль алар өчен аеруча мөһим. Ул чараны оештыручыларга зур рәхмәт сүзләре җиткерде.

16 декабрь көнне фестиваль кысаларында «Марокко Патшалыгы һәм Россия Федерациясе арасында сәяси, икътисади һәм мәдәни бәйләнешнең перспективалары» дип аталган «түгәрәк өстәл» узды.

